БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
18 апрель 2024 ел

**КАРАР**
№ 250

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы», «Норма авыл җирлеге», «Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чикләрен кушымтада бирелгән карта-схема нигезендә үзгәртү инициативасы белән чыгарга.

2. Әлеге Карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына әлеге муниципаль берәмлекләрнең чикләрен тәкъдим ителә торган итеп үзгәртү буенча фикерләрен җиткерергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча басылырга, «ХЕЗМӘТ» басма-редакция газетасында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма һәм Сосна авыл җирлекләренең мәгълүмат стендларында урнаштырылырга тиеш.


4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р.Р.Нотфуллин

Балтач район Советынын
карарына кушымта
18.04.24 № 250

# Карта-схема
## границ муниципальных образований с учетом изменений




Условные обозначения:

- граница Балтасинкого муниципального района

- границы муниципальных образований

- административные центры поселений

- населенные пункты

- территория Сосновского сельского поселения Балтасинского муниципального района, включаемая в состав территории муниципального образования "пгт. Балтаси" Балтасинского муниципального района

- территория Норминского сельского поселения Балтасинского муниципального района, включаемая в состав территории муниципального образования "пгт. Балтаси" Балтасинского муниципального района